

Бу акцияне “Бердәм Россия” партиясе ярдәме белән vткәрелә.
Кадошкино районында яшәvче пенсия яшендәге кешеләр бу игелекле эштә актив катнашалар. Хатын-кызлар махсус хәрби операция сугышчылары очен жылы әйберләр бәйлиләр, алар фронтка гуманитар йок белән жибәрәләр.

Латышовка авыл жир-легендә яшәvчеләрнен акциядә ничек катнашулары турында авылнын “Бердәм Россия” партиясе беренчел бvлекчәсе сек-ретаре Надия Байчурина сойләде.
- Без “Герой очен жылылык” акциясенә дә кушылдык. Жылы әйберләр бәйләгән жылылык һәм мәхәббәт безнен яклаучыларга бирелvен бик телибез.
Олкән буын вәкилләре, «Изге нур» фольклор ансамбле әгъзалары инде профессиональ рәвештә оекбаш бәй-лиләр. Хатын-кызлар һәр оегына vз жаннарын салалар. Олкән буын гына тvгел, яшьрәкләр дә сугышчыларыбызга ярдәм итәргә теләк белдерделәр. Латышовка авыл жирлеге депутаты, оч авылга хезмәт кvрсәтvче фельдшер-акушерлык пункты модире Безрукова Татьяна да сарык йонынннан жылы оекбашлар бәйли. Апалары Голнара Вяльшина белән Галия Арюкова, пенсионерларнын бер олеше - Донская Надия, Тураева Равиля, Горбунова Галина кебек, йоннан оекбашларны ойләрендә бәйлиләр. Бәйләнгән әйберләр һәм акция кысаларында жыел-ган хатлар район китапханәсенә тапшырыла. Моннан “Бердәм Россия” партиясенен жирле бvлекчәсе районнан посылка формалаштырачак, сонынннан ул алдынгыларга юл тотачак.